ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

28.06.2024 № 599

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Капиталь төзелеш объектларын төзүгә һәм эксплуатацияләүгә кертүгә рөхсәт бирүне тәртипкә салу турында» 2009 елның 5 маендагы 468 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Капиталь төзелеш объектларын төзүгә һәм эксплуатацияләүгә кертүгә рөхсәт бирүне тәртипкә салу турында» 2009 елның 5 маендагы 468 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә төзелеш өчен башлангыч-рөхсәт документларын рәсмиләштерү тәртибе» дип аталган 1 нче кушымтаның 4.1.2 пунктындагы 4 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-аларга кертү критерийлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган җир кишәрлегендә ярдәмче файдаланудагы төзелмәләр һәм корылмалар төзү»

1.2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә төзелеш өчен башлангыч-рөхсәт документларын рәсмиләштерү тәртибе» дип аталган 1 нче кушымтаның 4.1.7 пунктындагы 2 абзацны, 4.1.8 пунктны төшереп калдырырга.

1.3. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә төзелеш өчен башлангыч-рөхсәт документларын рәсмиләштерү тәртибе» дип аталган 1 нче кушымтаның 4 бүлегендәге 4.1. пунктының 4.1.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.2. Түбәндәге очракларда төзелешкә рөхсәт таләп ителми:

1) эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле булмаган максатлар өчен физик затка бирелгән җир кишәрлегендә гараж төзү, реконструкцияләү, яки бакчачылык һәм яшелчәчелек өлкәсендәге законнар нигезендә билгеләнгән торак йортның бакча җир кишәрлегендә бакча йорты, хуҗалык корылмалары төзү, реконструкцияләү;

2) индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, реконструкцияләү ("Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзелештә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүдән, реконструкцияләүдән тыш);

3) капиталь төзелеш объектлары булмаган объектларны төзү, реконструкцияләү;

4) аларга кертү критерийлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган ярдәмче куллану төзелмәләре һәм корылмаларын җир кишәрлегендә төзү;

5) капиталь төзелеш объектларын һәм (яисә) аларның өлешләрен үзгәртү, әгәр мондый үзгәрешләр аларның ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгы конструктив һәм башка характеристикаларына кагылмаса һәм шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан артмаса;

6) капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау, шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 11 өлешендә күрсәтелгән очракта;

7) җир асты байлыклары турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әзерләнгән, килештерелгән һәм расланган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проекты яисә җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшләр башкаруга башка проект документациясе нигезендә каралган бораулау скважиналарын төзү, реконструкцияләү;

8) 1,2 мегапаскальгә кадәр басым астында табигый газ транспортлау өчен билгеләнгән объектларны төзү, реконструкцияләү;

9) элемтә чараларын урнаштыру өчен билгеләнгән 50 метрга кадәр биеклектәге антенна терәкләре (мачталар һәм манаралар) урнаштыру;

10) бүтән очракларда, әгәр Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнары нигезендә төзелешкә рөхсәт алу таләп ителмәсә.»

1.4. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә төзелеш өчен башлангыч-рөхсәт документларын рәсмиләштерү тәртибе» дип аталган 1 нче кушымтаның 2.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Төзүче - үзе ия булган җир кишәрлегендә яисә башка хокук иясенең (аңа дәүләт (муниципаль) милкендәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), "Росатом" атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, "Роскосмос" космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары яки җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә билгеләнгән очракларда, килешүләр нигезендә үзләренең дәүләт (муниципаль) заказчысы вәкаләтләрен тапшырганнар яисә аңа "Территорияләрне үстерү фонды" гавами-хокукый компаниясе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 13_3 статьясы нигезендә килешүләр нигезендә үзләренең төзелеш алып баручы функцияләрен тапшырганнар) җир кишәрлегендә капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны, сүтүне, шулай ук инженерлык эзләнүләрен башкару, аларны төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау өчен проект документларын әзерләүне тәэмин итүче физик яисә юридик зат.»

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин